Латыпова Наиля Набиулловна, Учитель родного (татарского) языка, МБОУ «Степноозерская ООШ» Нурлатского муниципального района РТ

Тема. Синтаксический анализ сложносочиненных предложений.

Тезмә кушма җөмләләргә синтаксик анализ ясау**.** Тезмә кушма җөмләләрне гомумиләштереп кабатлау.

Максат: 1. Тезмә кушма җөмлә синтаксисы буенча теоретик материалны искә төшерү, кабатлау, ныгыту, гомумиләштерү; балаларның бәйләнешле сөйләм һәм иҗади эшчәнлекләрен арттыру;

2. Нурлат төбәгендә туып-үскән күренекле шәхесләр белән таныштыру.

3. Туган як белән горурлану тәрбияләү, аның мәдәнияте белән кызыксынуны арттыру.

Җиһазлау: тест, карточкалар, презентация.

Дәреснең тибы: кабатлау дәресе.

Дәреснең барышы.

I. **Оештыру моменты.**
   1. Исәнләшү.
   2. Дәреснең эпиграфы белән таныштыру.

Туган як һәркемгә изгедер,
Булганга бары тик бер генә,
Үз туган җиреңдә яшәүнең
Кадерен бел генә, бел генә
Ф. Мөхәммәтова

   3. Эпиграф буенча әңгәмә үткәрү.
      - Бу нинди җөмлә?
      - Теманы укучылар белән берлектә чыгару
   4. Максатның беренче өлешен аңлату
   5. Актуальләштерү. Тест эшләү һәм тикшерү.
   6. Әңгәмәне дәвам итү.
   7. Эпиграфта сүз нәрсә турында бара? (слайд)
      - Ни өчен мин мондый эпиграф сайладым дип уйлыйсыз?
      - Димәк, без бүгенге дәресебездә туган төбәк, танылган шәхесләр турында сөйләшәчәкбез. Бигрәк тә үзебезнең төбәктә туып-үскән шагыйрьләр турында сөйләшербез.
      - Сез безнең төбәктә туып-үскән нинди танылган шәхесләрне беләсез? (Т. Галиуллин, А. Халиков....)

II. **Яңа төшенчәләр бирү.**

1 С. Зәйнетдинова. Ф. Тямаев, Р. Насыйбуллин, Ф. Мөхәммәтова турында әңгәмә үткәрү:

- Аларның иҗаты турында тезмә кушма җөмләләр төзеп язу, дөреслеген тикшерү, анализ ясау.

2. “Нурлатым, әй Нурлат” җырының тексты белән эшләү. (слайд)
-- Бу җыр сезгә танышмы?
-- Аның турында ниләр беләсез?
-- Текстан тезмә кушма җөмләләрне табу, аларга телдән синтаксик анализ ясау.
3. Ике өстәлгә дә карточкалар тарату. 1 Ф. М.өхәммәтова, Г. Сәгыйров турында текст

Тыныш билгеләрен куеп күчереп язарга, тезмә кушма җөмләләрнең схемаларын төзеп, төрләрен билгеләргә.
4. Эшләрне тикшерү. Текст буенча әңгәмә үткәрү. (слайд)
5. Физкультминутка. **“Нурлатым, әй Нурлат”** җырына бию, көй туктагач, парлашып басу. Сорауларга җавап бирү.
--Тезмә кушма җөмләдәге гади җөмләләр үзара нинди бәйләнештә була?
-- Тезмә кушма җөмләнең нинди төрләре була?
-- Теркәгечле тезмә кушма җөмләдә нинди бәйләүче чаралар кулланыла?
-- Теркәгечсез тезмә кушма җөмләдә нинди бәйләүче чаралар кулланыла?

III. Белемнәрне ныгыту.

1. Г. Кариев турында мәгълүмат бирү.(слайд)
2. Текст белән эшләү. Күп нокталар урынына төшеп калган теркәгечләрне куеп күчереп язарга.(слайд)
3. Текст буенча әңгәмә үткәрү.
   - Кариев турында сез ниләр белдегез?
   - Аның исемен мәңгеләштерү өчен ниләр эшләнгән һәм эшләнә?
4. Аның киләчәккә булган өмете акланганмы? Шул турыда тезмә кушма җөмлә кулланып текст языгыз.(слайд)
5. Эшләрне тикшерү.

IV.Өй эше бирү.

1нче төркем- карточкалар буенча эш.

2нче төркем- иҗади эш. Г. Сәгыйров – көчле рухлы шәхес.Аның турында мәгълүмат туплап, тезмә кушма җөмләләр язып килергә.(слайд)

V. Йомгаклау, нәтиҗәләр ясау.

-- Бүгенге дәрестә сез үзегез өчен нинди яңалык алдыгыз?

Билгеләр кую.